**Садри Максудиның тууына 135 ел тулу уңаеннан**

# Татар милләтенең арысланы



«Милләт образауный кешеләргә һәм милләт файдасын һәртөрле шәхси мәнафигыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендә кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ».

***Г. ТУКАЙ.***

**(Башы 22нче санда)**

## Садри Максуди француз телен өйрәнә

Ул башта Төркиягә, ә аннан берникадәр вакыт яшәп, бераз француз теленнән дәресләр алгач, тәвәкәлләп, Франциягә китә. Бөтенләй дә диярлек французча белмәгән, акчасы, танышбелешләре булмаган С. Максуди үзенең зирәклеге, тырышлыгы, чыдамлыгы аркасында бөтен авырлыкларны җиңеп, һәммәсенә түзеп, бер ел эчендә француз телен өйрәнеп, Парижның Сорбонна университетының хокук факультетына укырга керә һәм дүрт елда аны тәмамлап тә чыга. Ул хокук дәресләреннән тыш, фәлсәфә һәм социология дәресләренә дә йөри. Монда укыганда аңа даими матди ярдәм күрсәтүче булмый, шуңа күрә ул Россиядәге төрле газеталарга (шул исәптән, «Тәрҗеман»га да) хәбәр, мәкаләләр язарга, рус теленнән дәресләр бирергә мәҗбүр була. Ләкин авырлыкларга да карамастан, Франциядә узган еллар романтик рухлы С.Максуди күңелендә матур хатирәләр калдыра, чөнки ул анда үзенә гомерлек дуслар, фикердәшләр таба: Парижда Йосыф Акчура, Яхья Кемал (булачак төрек язучысы) һәм башкалар белән дуслаша, алар белән төрки халыкларның үткәне, киләчәге турында кайнар бәхәсләр алып бара.

## Садри Европа зыялылыгын сеңдерә

Бөтен нәрсәне белергә омтылган Садри Максуди тырышып укудан тыш, Парижда яшәүче халыкның төрле катламнарының тормыш-көнкүреш, уйфикерләре белән дә кызыксына: ул студентлар яшәгән чардакларда да, эшчеләр яшәгән арзанлы фатирларда да еш була. Аны ул елларда аксөякләрнең әдәби салоннарында да күрергә мөмкин булган, ул хәтта моның өчен үзенә фрак та тектергән. Әдәбиятсәнгать яраткан Садри Максуди театрларга да еш йөри, музейларда да була, ә каникул вакытларында Франция буйлап сәяхәткә дә чыгып китә.

## Садри икенче роман яза

Парижда укыган елларында җитәрлек дәрәҗәдә матди ярдәм алып тормаган Садри Максуди гәҗитләргә мәкаләләр язып кына акча эшләп булмаганлыгын тиз аңлый һәм Америка язучысына ияреп, «Йөз ел соңара» дигән роман яза. Аның бу романы 1906 елда «Тәрҗеман» гәҗитендә СМ. имзасы белән басылып чыга. Шулай ук аның ул чорда французча бер пьеса да язып караганы билгеле булды. Кульъязма Садри Максудиның оныгы Г. Пултарда саклана.

## «Тәрҗеман»га - 20 ел!

1902 елда, инде Парижга барып, урнашып, университетта укый башлагач, Садри Максуди Исмәгыйл бәк Гаспринскийдан хат ала, ул аңа тиздән «Тәрҗеман» гәҗитенең 20 еллыгы булачагы турында яза.

Әлеге хаттан соң Садри Максуди уйланып йөри, аны бу уңайдан төрки халыклар арасында бернинди әзерлек эшләре дә алып барылмавы борчый. Ул: «Әгәр бу хәл башка алдынгы милләтләрдә булса, бер юбилей үткәрерләр иде, ул милләт үзенең милләтпәрвәрләренә олы хөрмәт, ихтирам күрсәтер иде», дип көенә. Садри Максуди сабакташы Йосыф Акчура белән киңәшеп, бу юбилей мөнәсәбәте белән Төркиядә һәм Россиядә яшәүче танылган зыялыларның И. Гаспринскийга хатлары рәвешендә бер китап чыгарырга уйлыйлар һәм үзләренең теләккиңәшләрен әйтеп, барлыгы йөздән артык кешегә хат язалар.

## Милләтсөярләр җыены

Бу китапчык Россия төркиләре арасында И.Гаспринскийның «Тәрҗеман» гәҗитенең 20 еллык юбилеен уздыру өчен нигез, бер этәргеч була. 1903 елда Бакчасарайда милләтсөярләрнең җыелышуы «бер милли конгресс рәвешен ала, төрле өлкәләрдән килгән төркиләр һәм Россия төркиләре өчен милли мәдәниятләрен үстерүдә, диннәрен, телләрен саклауда русларга каршы тору өчен бер киңәш мәҗлесе булды», дип яза С.Максуди үзе бу турыда соңыннан. С.Максуди әлеге бәйрәмгә үзе кайта алмаса да, үзләренең әлеге юбилейны уздыруда этәргеч булулары белән бик горурлана.

## Бердәм булганда гына телне һәм динне саклап була

«Йокымсырап яткан татар халкының хәятенә җан өрүче» И.Гаспринский үзе туктаусыз төрки халыкларның бердәм бер гаилә булып кына мәдәниятләрен, икътисадларын тәрәккый итә алачаклары турында аңлата һәм төрки халыкларның бердәм булганда гына телләрен-диннәрен саклап кала алачаклары турындагы фикеренә гомере буе тугрылыклы кала. Ә аның шәкерте, остазының бу фикеренә кушылып, 1907 елдан башлап, Россия Дәүләт думалары депутаты буларак, Дума мөнбәреннән изелгән, хурланган мөселман халыкларының хокукларын бертигез яклап, ялкынлы чыгышлар ясый. Татар халкында миллият хисен уяту, тәрбияләүдә, милли хәрәкәткә юнәлеш бирүдә әһәмиятле роль уйнаган шәхесләрнең берсенә әверелә. Татар милли хәрәкәте идеологларының иң авторитетлысына әйләнгән С.Максуди, еллар узгач, бу юлда зур тәҗрибә туплагач, үзенең «рухи атасы»ның милләткә хезмәттә озак еллар буена үз иңнәрендә нинди авыр йөк күтәреп барганын яхшы аңлаячак. «Мөхтәрәм мөгаллим, Сезне милләт тарафыннан Русиянең бөтен нокталарында исламнар тарафыннан билгеләп үтелә торган мактаулы олуг бәйрәм белән котлыйм. Сезнең яшәдем дип әйтергә хакыгыз бар. Сез бүген һәр мөселманның фикерендә милләтнең тарихысыздыр. Сезнең хәятыгыз мисалы без - Русия мөселманнары өчен үрнәктер», дип язачак ул 1908 елның 13 маенда «Йолдыз» гәҗитендә «Тәрҗеман»ның 25 еллык юбилее уңаеннан.

## Юрист дипломы алып Садри ватанга кайта

1906 елда биш ел иленнән аерылып яшәгән С.Максуди Сорбоннаны тәмамлап, юрист дипломы алып, милли хисләр белән тулып, үзен милләт тәрәккыятенә хезмәт итәргә хәзерләп, Россиягә кайта. Шушы елдан алып аның татар милләтенә фидакарьләрчә хезмәткә багышланган эшчәнлеге башлана.

## Садри - депутатлыкка кандидат

1906 елның 16-20 августында Түбән Новгородта «Мөселман иттифакы» партиясенең III Корылтае уздырыла һәм аның эшендә Исмәгыйл Гаспринский, Йосыф Акчураларның чакыруы буенча С.Максуди да катнаша. Ул аның сәясәт комиссиясендә эшли, әлеге партиянең Идарәсенә сайлана. Шушы партия тарафыннан аның кандидатурасы 2нче Дәүләт думасына депутатлыкка тәкъдим ителә.

## Садри - депутат

Садри Максудиның, шулай итеп, 1907 елдан 1912 елга кадәр булган 2-3нче Дәүләт думаларындагы депутат буларак эшчәнлеге, ягъни ил күләмендәге рәсми сәясәттәге эшчәнлеге башлана. 2нче Думада ул Президиум әгъзасы итеп, 3нче Думада исә Мөселман фракциясе секретаре итеп сайлана.

## Садриның һәр чыгышы - вакыйга

1907-1912 еллар - татар вакытлы матбугатында өзлексез кыйналуга, тәнкыйтьләүләргә дә карамастан, III Думадагы сигез кешедән торган Мөселман фракциясе һәм аның иң эшчән депутатларыннан булган С. Максудиның сәяси, милли эшчәнлегенең иң актив еллары. Ул 2нче һәм 3нче Дәүләт думалары утырышларында татар һәм мөселман халыкларының хокукларын яклап, барлыгы 15ләп, ә төрле комиссияләрдә исә 100дән артык чыгыш ясый. Бу чыгышларның барысы да диярлек рус газеталарында басылып баралар һәм җәмәгатьчелектә киң яңгыраш алалар. Аның Дума утырышларында ясаган һәр чыгышы вакыйгага әйләнә. 1912 елда IV Думага сайлауларда көчемсез милке юк дигән сылтау белән С.Максуди кандидатурасы уздырылмый һәм, шулай итеп, өченче Думаның иң эшчән депутаты булган С.Максуди кандидатлар исемлегенә кертелми. Өченче Думага депутат булып сайланмаса да, ул Россия хөкүмәтенең милли сәясәтен татар милләтенә аңлату, җиткерү буенча зур эш алып бара. Россия Дәүләт думасында закон проектлары каралганда әлеге законның татар халкына, мөселман халыкларына файдасы барлыгын яки юклыгын җентекләп аңлаткан мәкаләләре ул елларда «Йолдыз» гәҗитендә һәрдаим басылып торалар.

## Садри миллионер кызына өйләнә

1910 елда утыз яшенә кадәр буйдак булып яшәгән С.Максудиның шәхси тормышында да зур үзгәреш була: ул миллионер Шакир Рәмиевнең кызы Камиләгә өйләнә. Туйга татар дөньясының барлык танылган байлары, зыялылары чакырыла, бу вакыйга турында барлык татар гәҗитләре дә диярлек язып чыга.

**(Дәвамы бар)**

**Мәгълүматны Шамил БАҺАУТДИН туплады.**

**Горурланырлык ирләребез**

# Полковник Таһир Әбүзәровны ялга озаттылар

Әбүзәровлар Самар төбәге өчен таныш фамилия. Бигрәк тә Теплый Стан халкына. Борһан ага Әбүзәров күп еллар буена авылда күмәк хуҗалык рәисе булып хезмәт итте. Авылдашлары өчен кадерле вә газиз кеше булып күңел түрләренә кереп калды.

Декабрьнең 12ндә Борһан аганың углы - полиция полковнигы дәрәҗәсенә күтәрелгән Таһир Әбүзәровны хезмәттәшләре лаеклы ялга озаттылар.

Генерал-майор Николай Турбовец Таһир Әбүзәровның узган хезмәт юлына җентекләп тукталып, хөрмәтле вә газиз сүзләр яңгыратып, зал тулы халык алдында Таһир әфәндегә эчке эшләр идарәсе пенсионеры кенәгәсен тапшырды.

Борһан углы Таһир Әбүзәров үзенең хезмәт юлын 1981 елда өлкәбезнең Богатое районында башлап җибәрә. 2008 елда аны Похвистнево төбәгенә зур урынга җибәрәләр. Хезмәт дәверендә Таһир әфәнде Төньяк Кавказга кат-кат командировкага җибәрелә. Командировка сүзе бик матур булса да, аның эчтәлеге - сугыш!

Борһан углы Таһир Әбүзәровның күкрәген орден һәм медальләр бизи. Милициядә һәм полициядә медальләрне тикмәгә генә бирмиләр. Анда һәр бүләк үлемне җиңгәнгә бирелә.

Таһир әфәнде гомеренә спортчы булды һәм ул җитәкләгән команда күп ярышларда җиңүгә лаек була.

Барлык коллегалары да Таһир әфәндегә соклануларын белдерделәр, аның кешелек сыйфатларына басым ясадылар.

Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Туктаргали углы Рифкат Хуҗин авылдашы, мөгаллиме, намус бизмәне булган Таһир Әбүзәровны тәбрикләп, аңа авылдашларының рәхмәтен ирештерде һәм бүләкләр тапшырды.

***Шамил БАҺАУТДИН.***

**Котлау**

# Яңа еллар мөбарәк булсын!

Халкыбыз яшәешендә рухыбызны күтәреп, рухландырып җибәрүче көннәр бар.

Һәр атнаны матур, чиста киемнәребезне киеп, җомга намазына баруларыбыз безгә мәңгелекне искә төшереп тора.

Корбан һәм Ураза гаетләрендә мәчетләргә җыелып, Ходай Тәгалә каршында намусларыбызны пакьләргә тырышабыз.

Без, мөселманнар, елына ике мәртәбә Яңа елны каршы алабыз. Әле яңа гына, ноябрьнең 15ндә, Һиҗри буенча 1434 ел башлануын намазларыбыз белән билгеләп узган идек.

Без бөек Россия Федерациясендә милләтебезнең барлыгын һәм бердәмлеген куәтләп дөнья куабыз. Һәм, шул дәүләтнең гражданнары буларак, Милади буенча килгән 2013 елны да зурлыйбыз.

Барлык татар-башкортларыбызга, мөселманнарга ихлас күңелебездән изгелек, сәламәтлек телибез, чөнки сәламәтлеккә тиң башка нигъмәт юк.

**Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Минәхмәт Хәлиуллов.**

**Самар татарларының рәсми сайты: http://tatarlarsamara.org**

Мөхәррир - Наилә Сабирҗанова.